**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 13 июль № 510

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында ирекле хәрәкәткә булышлык күрсәтү турында» 2012 ел, 5 октябрь, 830 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында ирекле хәрәкәткә булышлык күрсәтү турында» 2012 ел, 5 октябрь, 830 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында ирекле хәрәкәтне үстерү һәм аңа булышлык күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ»;

1 нче пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга;

карарның 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына йөкләргә»;

карарның текстында тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы» сүзләрен тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2013 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасында ирекле хәрәкәтне үстерү концепциясен тормышка ашыру буенча 2013 елга чаралар планын үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган Ирекленең (волонтерның) шәхси кенәгәсе турындагы нигезләмәнең 3.2 нче пунктында «оешма (учреждение) мөһере белән расланган» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\510.docx